СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

07.11.2025 ел с. Шеланга № 2-14

Торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен Шилангы авыл җирлеге составына керүче Шилангы авылы торак пункты территориясенең бер өлеше чикләрен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Шилангы авыл җирлеге Уставы статьясы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Гражданнар яшәгән түбәндәге территорияләр чикләрендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен территориянең бер өлеше чикләрен билгеләргә:

Шилангы авылы:
Октябрь урамында №4тән №120гә кадәр торак йортлары;
Совет урамында №1дән №37гә кадәр торак йортлары;
Энергетиклар урамында №1дән №23гә кадәр торак йортлар;
Мәктәп урамында №2дән №50гә кадәр торак йортлары;
М.Горький урамында №1дән №87Ага кадәр торак йортлар;
Кооператив урамында №2дән №27гә кадәр торак йортлар;
К.Цыпкин урамында №1дән №23кә кадәр торак йортлар;
М.Горький урамында №1дән №87Ага кадәр торак йортлар;
Яр буе урамында №2Адан №100гә кадәр торак йортлар;
Завод урамында №7Адан №42гә кадәр торак йортлар;
Куйбышев урамында №2дән ;44 кә кадәр торак йортлар;
Төзүчеләр урамында №3тән №51гә кадәр торак йортлар;
Заречная урамында №1дән №6га кадәр торак йортлары;

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Шилангы авыл җирлеге Советының социаль мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров